**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге составына керүче Мәләкәс авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

21октябрь, 2023 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 21 октябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2024 елда яшәү урыны буенча Мәләкәс авыл җирлеге Мәләкәс авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- янгын сүндерү машинасы өчен гараж төзү (төзелеш материаллары, җиһазлар сатып алу);

-торак пункт чикләрендә электр белән тәэмин итүне оештыру (яктырткычлар һәм электр җиһазлары сатып алу, монтажлау);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (кече архитектура формаларын урнаштыру һәм тоту);

- МКД территориясен төзекләндерү;

-зиратны саклау өчен материаллар сатып алу һәм урнаштыру.

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы **711** кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 711 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы **390** кеше тавыш бирде;

«Юк» -0.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Мәләкәс авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2024 елда яшәү урыны буенча Мәләкәс авыл жирлеге Мәләкәс авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- янгын сүндерү машинасы өчен гараж төзү (төзелеш материаллары, жиһазлар сатып алу);

-торак пункт чикләрендә электр белән тәэмин итүне оештыру (яктырткычлар һәм электр жиһазлары сатып алу, монтажлау);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (кече архитектура формаларын урнаштыру һәм тоту);

- МКД территориясен төзекләндерү;

-зиратны саклау өчен материаллар сатып алу һәм урнаштыру.

3. Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Мәләкәс авылы гражданнар жыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка житкерергә.

4. Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл жирлеге Мәләкәс авылы гражданнар жыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар жыенында рәислек итүче,
Мәләкәс авыл жирлеге Башлыгы Ю.П.Васильев